**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**“АЕРЫМ ПРЕДМЕТЛАР ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНЕЛӘ ТОРГАН**
**2НЧЕ АЛЕКСЕЕВСК УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ”**
**МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЯСЕ**

| «КАРАЛДЫ» | «КИЛЕШЕНДЕ» | «РАСЛАНДЫ» |
|---|---|---|
| Методик берләшмә житәкчесе<br>__________И.Х.Замалиева<br>МБ утырышы беркетмәсе<br>№1 «25» август 2016 ел | Директор урынбасары<br>__________Л.Р.Ягудина<br>«27» август 2016 ел | Мәктәп директоры<br>__________Л.Н.[illegible]нина<br>Педагогик совет беркетмәсе<br>**233** нче номерлы боерык белән гамәлгә кертелде.<br>31 нче август 2016 ел |

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Аношина Маргарита Николай кызы
9 «А» сыйныфы өчен татар теленнән
эш программасы

Педагогик киңәшмә
Утырышында каралды.
Беркетмә №1
31 август 2016 ел

**2016 - 2017**

## I. Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре

**Сыйныф**: 9 “А”

**Укытучы:** Аношина М.Н.

**Уку планы буенча**

**Татар теленнән:** 68 сәг.

**Атнага:** 2 сәг.

**Контроль диктант: 1**

**Сүзлек диктанты: 2**

**Кереш контроль тест:1**

**Сочинение: 1**

**Изложение: 1**

**Контроль эш: 4**

Дәреслек: Татарча да яхшы бел. Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 9 нчы сыйныфы өчен татар теле дәреслеге (рус телендә сөйләшүче балалар өчен). Авторы: Р.Р. Нигъмәтуллина. Казан. “Мәгариф” нәшрияты.2008

Программа түбәндәге документлар нигезендә төзелде:

1. Программа: Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы. Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы (1 — 11 нче сыйныфлар). Төзүче – авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р. Л. Малафеева, 2014 ел.
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең төп гомуми белем бирү баскычында башлангыч гомуми белем бирү программасы.
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең 2016-2017 уку елына укыту планы (№1 педсовет протоколы, 31 август 2016 ел).

**Татар теленә өйрәтүнең предмет нәтиҗәләре.**

- Укучыларның коммуникатив компетенциясен (аралашу осталыгын) үстерү, ягъни, татар телендәсөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашу күнекмәләре булдыру;
- коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә аралашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, киң күңелле әңгәмәдәш булу;
- “Татар теле” предметына карата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну булдыру һәм, шулар нигезендә, белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштергә шартлар
- шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;
- әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;

- текстлардагы төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;
- “гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек” төшенчәләрен кабул итү, “башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык”, “кеше кадерен белү” кебек хисләр формалашу.
- Урта белем бирү баскычында татар теле укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук,реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (***танып белү, регулятив, коммуникатив)*** формалаштыруга хезмәт итә.Татар теле укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (***танып белү, регулятив, коммуникатив)*** формалаштыруга хезмәт итә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар текст, күрмә-график рәсемнәр, хәрәкәтле яисә хәрәкәтсез сурәтләр, ягъни, төрле коммуникацион технологияләр аша тапшырыла торган мәгълүмати объектлар белән эшләү тәҗрибәсе ала; презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрәнә*; у*кучыларда, компьютер яисә ИКТ нең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алу күнекмәләре формалаша.

***Танып белү нәтиҗәләре:***

- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
- иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру;
- объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
- төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
- тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.

- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;
- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
- уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;
- билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;
- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;
- дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү;
- дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү.

- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
- әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
- аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);
- парларда һәм күмәк эшли белү;
- мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;
- әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

## II. Укыту предметының эчтәлеге

9 нчы сыйныфта татар теле буенча эш программасына: сүз һәм җөмлә, татар җөмләсендә сүз тәртибе, җөмләдә сүзләр бәйләнеше, тезүле бәйләнеш, ияртүле бәйләнеш, ике составлы

һәм бер составлы җөмләләр, җыйнак һәм җәенке җөмләләр, тулы җөмләләр һәм ким җөмләләр, җөмләнең тиңдәш кисәкләре, эпистоляр жанр текстларының үзенчәлекләре, теркәгечләренең җөмлә төзүдә кулланылышы, кушма җөмлә турында гомуми төшенчә, кушма җөмлә төзүче җөмләләрнең бер-берсенә бәйләнеше, тезмә кушма җөмлә турында гомуми мәгълүмат, аларда бәйләүче чаралар, тезмә кушма җөмләләр һәм алар янында тыныш билгеләре, иярченле кушма җөмләләр турында гомуми мәгълүмат, аналитик иярчен җөмләләр, аларның үзенчәлекләре, аналитик иярчен җөмләләр янында тыныш билгеләре, синтетик иярчен җөмләләр, аларның үзенчәлекләре, синтетик иярчен җөмләләр янында тыныш билгеләре, татар һәм рус телләрендә тезмә һәм иярченле кушма җөмләләр, иярчен ия җөмлә, иярчен хәбәр җөмлә, иярчен тәмамлык җөмлә, иярчен аергыч җөмлә, кушма җөмлә төрләрен һәм тыныш билгеләрен кабатлау, иярчен вакыт җөмлә, иярчен урын җөмлә, иярчен рәвеш җөмлә, иярчен күләм җөмлә, иярчен сәбәп җөмлә, иярчен максат җөмлә, иярчен шарт җөмлә, иярчен кире җөмлә, иярченле кушма җөмләләрне кабатлау, иярченле кушма җөмләдә бәйләүче чаралар, графика һәм орфография, сузыкларның дөрес әйтелеше һәм язылышы, тартыкларның дөрес әйтелеше һәм язылышы, сүз ясалышы, ирен гармониясе, сингармонизм законы, исемнәрнең килеш белән төрләнеше, исемнәрнең тартым белән төрләнеше, изафә бәйләнеше, тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше, сыйфатның лексик грамматик мәгънәсе һәм морфологик-синтаксик билгеләре, санның лексик грамматик мәгънәсе һәм морфологик-синтаксик билгеләре, фигыльнең лексик грамматик мәгънәсе һәм морфологик-синтаксик билгеләре, фигыльнең биш юнәлеше, аларның мәгънәләре, алмашлыкларның лексик грамматик мәгънәсе һәм морфологик-синтаксик билгеләре, затланышлы фигыльләр, затланышсыз фигыльләр, сүз төркемнәре, җөмлә төрләре, җөмлә кисәкләрен кабатлау буенча темалар кертелә.

Татар теле буенча эш программасы яңа темаларны нәтиҗәле үзләштерүне күздә тота. Моның өчен уку елы башында һәм ахырында кабатлауга зур игътибар бирелә. Һәр тема үткән материалны кабатлау, контроль эш, сүзлек диктанты, изложение, бәйләнешле сөйләм үстерү, тыңлап һәм укып аңлау белән тәмамлана.

Укучыларның сүзлек запасын баету өчен 9 нчы сыйныфта татар теле буенча эш программасында сүзлекләр белән эшләү даими алып барыла.Сүзлекләр белән эшләүнең иң мөһим таләбе - укучыларның таныш булмаган сүзләрне күрә,сүзлекләргә мөрәҗәгать итә һәм аларны куллана белергә өйрәтү.

Татар теле буенча эш программасы укучыларның татар телендә сөйләшүчеләр белән язмача аралашу күнекмәләре булдыруга юнәлтә. Урта баскычта рус телле балаларга татар теле һәм әдәбиятын укыту максатлары берничә аспектны үз эченә ала: танып белү, үстерү, тәрбия, белем бирү.

-“Татар теле һәм әдәбияты” предметынакарата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну булдыру һәм шулар нигезендә белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштергә шартлар тудыру.

-шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;

-тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.

- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;

- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру.

**Татар телен өйрәтүгә таләпләр:**

Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләренең исемнәрен әйтә, аларга сорау куя,аера белү.

Гади һәм кушма җөмләләрне аера белергә өйрәтү.

Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрне сөйләмдә куллана белү күнекмәләрен булдыру.

Җыючы, каршы куючы, бүлүче теркәгечле кушма җөмләләрне сөйләмдә куллану.

Иярчен хәл җөмләләрнең **иярчен урын җөмлә, вакыт җөмлә, сәбәп җөмлә, максат җөмлә, шарт җөмлә, кире җөмләләре** белән таныштыру һәм аларны сөйләмдә урынлы кулланылуына ирешү.

Тезмә һәм иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләрен дөрес куя һәм аларны тиешле интонация белән әйтә белү.

**Педагогик технологияләр һәм укыту чаралары:**

-мәгълүмати-коммуникатив технология (компьютер, Интернет, интерактив такта);

-шәхси – индивидуальләштерү технологиясе;

-проектлы укыту технологиясе;

-уенга корылган педагогик технология.

## III.Төп уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планлаштыру

| № | Дәрес темасы | Укыту эшчәнлеге | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1. | Ярый әле мәктәп бар! Исем фигыль. | Диалог төзү | 3.09 |
| 2. | Хәзерге заман сыйфат фигыль. | Ситуатив күнегүләр эшләү | 6.09 |
| 3. | Билгесез үткән заман хикәя фигыль. Фигыль юнәлешләре. | Монологик сөйләм төзү | 10.09 |
| 4. | **Кереш контроль тест**. | **Кереш контроль тест**. | 13.09 |
| 5. | Билгесез үткән заман фигыльләрне ныгыту. **Сүзлек диктанты** | Хаталар өстендә эш **Сүзлек диктанты** | 17.09 |
| 6. | Нишләгән өчен? Нишләмәгән өчен? сораулары. | Диалог төзү | 20.09 |
| 7. | Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре | Ситуатив күнегүләр эшләү | 24.09 |
| 8. | Нинди максат белән? грамматик конструкциясе | Сорауларга җавап кую | 27.09 |
| 9. | Хәзерге заман сыйфат фигыль | Сөйләмдә куллану | 1.10 |
| 10 | Изафә бәйләнешле исемнәр. Һөнәр ияләре. | Монологик сөйләм | 4.10 |
| 11 | Хат язабыз. | Хат язу | 8.10 |
| 12 | Гади һәм кушма җөмләләр | Ситуатив күнегүләр эшләү | 11.10 |
| 13 | **Контроль эш №1. Тема: Ял итә беләсеңме?** | **Контроль эш** | 15.10 |
| 14 | Хаталар өстендә эш. Хәл фигыльләр | Хаталар өстендә эш | 18.10 |
| 15 | Дуслык. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр. | аудирование | 22.10 |
| 16 | Бәйрәмнәр. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр. | Монолог төзү | 25.10 |
| 17 | сәнгат. Ярыймы, ярамыймы? | Сәнгатьлелек өстендә эш | 29.10 |
| 18 | Йомгаклап кабатлау дәресе.Күнегүләр эшләү. | Ситуатив күнегүләр эшләү | 8.11 |
| **Тема: Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый (4 сәг.)** | | | |
| 19 | Ясалма исемнәр | Диалог төзү | 12.11 |
| 20 | Боерык фигыль. Бөек Ватан сугышы. | аудирование | 15.11 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 21 | Нишләр иде? Нишләмәс иде.<br>Татарстанның Советлар Союзы геройлары.<br>Муса Җәлил һәм Андре Тиммерманс | Сорауларга җавап бирү | 19.11 |
| 22 | Нишләп? Нишләмичә? сораулары.<br>Моабит дәфтәрләре. Җәлилчеләр. | Ситуатив күнегүләр эшләү | 22.11 |
| **Тема: Сәламәтлек – зур байлык (10 сәг.)** | | | |
| 23 | Спорт төрләре | Монологик сөләм | 26.11 |
| 24 | Җыючы , каршы куючы теркәгечле кушма җөмләләр | Ситуатив күнегүләр эшләү | 29.11 |
| 25 | Бүлүче теркәгечле кушма җөмләләр. **Сүзлек диктанты**. | **Сүзлек диктанты**. | 3.12 |
| 26 | Телләр белгән илләр гизгән. Минем виртуаль дөньям | Монологик сөләм | 6.12 |
| 27 | **Контроль эш №2 Тема: «Сәламәтлек – зур байлык»** Сүз төркемнәре | **Контроль эш** | 10.12 |
| 28 | Фразеологизмнар | Парларда эшләү | 13.12 |
| 29 | **Контроль диктант. Урман.** | **Контроль диктант** | 17.12 |
| 30 | Хаталар өстендә эш. Хәл фигыль | Ситуатив күнегүләр эшләү | 20.12 |
| 31 | Хаталар өстендә эш. Сүз төркемнәрен кабатлау | Хаталар өстендә эш | 24.12 |
| 32 | Йомгаклап кабатлау дәресе.Күнегүләр эшләү. | Ситуатив күнегүләр эшләү | 10.01 |
| **Тема: Һөнәр сайлау(10 сәг.)** | | | |
| 33 | Иярчен вакыт җөмләләр | Парларда эшләү | 14.01 |
| 34 | Иярчен урын җөмләләр | Ситуатив күнегүләр эшләү | 17.01 |
| 35 | Иярчен рәвеш җөмләләр | Төркемнәрдә эшләү | 21.01 |
| 36 | Иярчен күләм җөмләләр | Индивидуаль биремнәр башкару | 24.01 |
| 37 | Иярчен максат җөмләләр | Ситуатив күнегүләр эшләү | 28.01 |
| 38 | Иярчен шарт җөмләләр | Диалогта куллану | 31.01 |
| 39 | Иярчен сәбәп җөмләләр | Монологик сөйләм | 4.02 |
| 40 | Иярчен кире җөмләләр | Ситуатив күнегүләр эшләү | 7.02 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 41 | **Сочинение. Дуслык авырлык килгәндә сынала.** | **Сочинение.** | 11.02 |
| 42 | Хаталар өстендә эш. Күнегүләр эшләү | Хаталар өстендә эш | 14.02 |
| **Тема: Без Татарстанда яшибез(10 сәг.)** | | | |
| 43 | Татарстанның икътисади хәле | Диалог төзү | 18.02 |
| 44 | Татар музыка сәнгать тарихы | Монолог төзү | 21.02 |
| 45 | Татар музыка сәнгать тарихы | Парларда эшләү | 25.02 |
| 46 | Татар театры сәнгате | Сәнгатьлелек өстендә эш | 28.02 |
| 47 | Татарстан шәһәрләре | Монолгик сөйләм | 4.03 |
| 48 | Нәрсәсе белән? соравы | Диалогта катнашу | 7.03 |
| 49 | **Контроль эш №3. Тема: Без Татарстанда яшибез** | **Контроль эш** | 11.03 |
| 50 | Хаталар өстендә эш. Иярчен җөмләләрне кабатлау | Хаталар өстендә эш | 14.03 |
| 51 | Психолог киңәшләре | Ситуатив күнегүләр эшләү | 18.03 |
| 52 | Йомгаклап кабатлау дәресе.Күнегүләр эшләү. | Ситуатив күнегүләр эшләү | 1.04 |
| **Тема: Табигать һәм кеше (15 сәг.)** | | | |
| 53 | Аның нишлисе килә\килми? грамматик конструкциясе | Диалог төзү | 4.04 |
| 54 | Һава торышы | Монолог төзү | 8.04 |
| 55 | Чиста һава - табигать байлыгы | Монолог төзү | 11.04 |
| 56 | **Изложение.**<br>**Кинога барганда.** | **Изложение.** | 15.04 |
| 57 | Кызыл китап, Гринпис . | Монолог төзү | 18.04 |
| 58 | Милли парк һәм тыюлыклар | Дәреслек өстендә эш | 22.04 |
| 60 | Проект “Авылым табигате” | Проект эшләү | 25.04 |
| 61 | Урманда әдәпле бул! | Парларда эшләү | 29.04 |
| 62 | Урманга ярдәм кирәк | Ситуатив күнегүләр эшләү | 2.05 |
| 63 | Поход - шәп ул! | Төркемнәрдә эшләү | 6.05 |
| 64 | -дип уйлыйм/дип саныйм структурасы | Ситуатив күнегүләр эшләү | 9.05 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 65 | **Йомгаклау контроль эш** | **Йомгаклау контроль эш** | 13.05 |
| 66 | Хаталар өстендә эш. Күнегүләр эшләү | Хаталар өстендә эш. | 16.05 |
| 67 | Кабатлап күнегүләр эшләү. | Ситуатив күнегүләр эшләү | 20.05 |
| 68 | Йомгаклап кабатлау дәресе | Ситуатив күнегүләр эшләү | |

Пронумеровано, прошнуровано
и скреплено печатью 9/девять листов
татарского языка
и литературы: Аношина М.Н.